Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-9**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI - 6 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районында идарә итүнең вакантлы вазифаларын һәм муниципаль хезмәт вазифаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазифаларын алмаштыруга кадрлар резервы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга тәңгәлләштерү максатларында, 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 1 мартындагы “Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турындагы Нигезләмәсен раслау турында” 96 номерлы Указы, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында Кодексы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI - 6 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районында идарә итүнең вакантлы вазифаларын һәм муниципаль хезмәт вазифаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазифаларын алмаштыруга кадрлар резервы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 16 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16. Кадрлар резервына кертүгә конкурслы сайлап алуны үткәрү турындагы хәбәр конкурслы сайлап алуны үткәрү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:";

1.2) 17, 17.1, 17.2,17.3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“17. Конкурста катнашырга теләк белдергән граждан Комиссиягә тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) фотография белән бергә әлеге Нигезләмәгә бирелгән 1 номерлы кушымтага ярашлы рәвештәге форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета;

в) паспорт яки аны алыштыручы документның күчермәсе (тиңдәшле документ конкурска килгәч шәхсән тәкъдим ителә);

г) зарури һөнәри белемне, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

нотариуста яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырылган очраклардан гайре) яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белем һәм квалификация турында документлар, шулай ук граждан теләге буенча өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирүне раслаучы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документларның нотариуста яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) гражданның Россия Федерациясе дәүләт граждannар хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулаучы авыруының булмавы турында документ.

17.1.Җирле үзидарә органында үткәрелүче конкурста катнашырга теләк белдергән әлеге органда муниципаль хезмәт вазифасын биләүче муниципаль хезмәткәр гаризаны Комиссиягә бирә.

17.2. Бүтән җирле үзидарә органында үткәрелүче конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр Комиссиягә гаризаны һәм тутырылган, имзаланган һәм үзе муниципаль хезмәт вазифасын биләгән җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотография белән тапшыра.

17.3. Тиешле документларның төп нөсхәләре дәгъва итүче тарафыннан конкурслы сайлап алуга килгәч күрсәтелә. Граждан тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өстәмә тикшерелергә мөмкин. Гариза кадрлар резервын формалаштыруга документларны теркәү журналында теркәлә. Гариза биргән гражданга документларны алу турында, исемлеген һәм алу датасын күрсәтеп, раслама бирелә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук саклау, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов